## СӘГАТЬЛӘР

*сүзләре һәм көе – Шамил Сагаутдинов*

1. «Сәгать ничә?» – дип сорадың,
   Елмайдың, серле итеп.
   Мин күзләреңә карадым,
   Соравыңны онытып.

   Шул минутта аңлаштылар,
   Кавыштылар безнең йөрәкләр.
   Ә бит, бәлки, очрашмас та идек,
   Бу дөньяда булмаса сәгатьләр!

**Кушымта:**

Кызарып яна шәфәкъләр,
Яңадан таңнар туа.
Туктаусыз йөри сәгатьләр,
Телләрен куа-куа.

Сәгать күпме генә йөрсен,
Бергә була телләре.
Гел шулай, берлектә үтсен
Сөйгән яр гомерләре!

2. Үтәр кышлар, үтәр җәйләр,
   Агар вакыт ташкыны,
   Бер дә тынмас яшь йөрәкләр,
   Табышырга ашкыныр.

   Барлык парлыларның гомерләре
   Булсын иде бәхетле!
   Кавышу сәгатьләре, барасы юллары
   Булсын иде хәерле!

**Кушымта.**

**Часы**

Стрелки часов то сходятся, то расходятся, но все равно они всегда вместе. Пусть же и влюбленные, как стрелки часов, никогда не расстаются друг с другом.